КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 июль г.Казань № 520

Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 26 июль, 520 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә даими пассажир йөртүләрне планлаштыру документын формалаштыру буенча эшләр максатларын, әзерләү процедурасын, эчтәлеген, составын билгели (алга таба – планлаштыру документы).

2. Планлаштыру документын әзерләүнең максатлары түбәндәгеләр:

муниципальара элемтәдә Татарстан Республикасы халкына транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

Татарстан Республикасы территориясендә даими муниципальара йөртүләрне үстерү юнәлешләрен билгеләү;

Татарстан Республикасында даими муниципальара йөртүләрне үстерүгә юнәлтелгән чараларны билгеләү һәм нигезләү.

3. Планлаштыру документын әзерләү өчен даими йөртүләрнең муниципальара маршрутлары системасы эшләве турында чын мәгълүматлар рәвешендә нигезләүче материалларны җыю һәм анализлау буенча фәнни-тикшеренү эшләре башкарыла.

Планлаштыру документын формалаштыру эшләре составы техник бирем белән билгеләнә.

4. Планлаштыру документы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

планлаштыру документын формалаштыру максатлары өчен халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең гамәлдәге системасын, муниципальара йөртүләрдә пассажир транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә сорауны, гамәлдәге һәм киләчәктәге социаль-икътисадый үсеш шартларын анализлау;

Татарстан Республикасы территориясендә даими йөртүләрнең муниципальара маршрутларында пассажирлар агымын сезонлап тикшерүләр мәгълүматлары;

Татарстан Республикасы территориясендә даими муниципальара йөртүләрне үстерү максатлары һәм өстенлекләре;

Территорияләр үсешен исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә даими муниципальара йөртүләр маршрутлары челтәрен формалаштыру буенча тәкъдимнәр, даими йөртүләрнең һәр маршрут буенча төрләрен нигезләү, йөртүләрнең төрен үзгәртү буенча тәкъдимнәр;

шәһәр яны һәм шәһәрара элемтәдә даими муниципальара йөртүләр маршрутларына хезмәт күрсәтү өчен хәрәкәттәге составка таләпләр;

Татарстан Республикасында автомобиль транспорты белән даими муниципальара пассажир йөртүләрне үстерүгә юнәлтелгән идарә, закон чыгару, норматив һәм оештыру-техник характердагы чаралар исемлеге, аларны тормышка ашыру өчен кирәкле финанс ресурсларын бәяләү белән;

даими муниципальара һәм төбәкара йөртүләр маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) соңгы туктау пунктлары сыйфатында файдалану рөхсәт ителә торган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан туктау пунктлары исемлеге;

даими йөртүләрне гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган транспорт чараларының Татарстан Республикасы территориясендә төнге вакытка тукталып урнашу урыннары;

җайга салынмый торган тарифлар буенча даими муниципальара йөртүләр маршрутларын оештырганда ачык конкурслар үткәрү чоры;

тиешле финанслау булганда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән өлешчә яки тулысынча түләнә торган җайга салына торган тарифлар буенча даими муниципальара йөртүләр маршрутларын оештырганда сатулар үткәрү һәм дәүләт контрактлары төзү чоры;

планлаштыру документын тормышка ашыруның нәтиҗәлелек күрсәткечләре системасы.

5. Планлаштыру документы проектын әзерләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алына:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары, йөртүчеләр һәм гражданнарның Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрелә торган автомобиль транспортында пассажирлар йөртүләр системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәре;

республиканы социаль-икътисадый үстерү, территориаль планлаштыруның гамәлдәге һәм киләчәктәге шартлары һәм территорияләрне планлаштыру проектлары;

автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж йөртү эшчәнлеген регламентлаучы норматив хокукый документлар.

6. Планлаштыру документын формалаштыру өчен эшләр башкаручыны билгеләү дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итәр өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

7. Планлаштыру документы биш ел чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

8. Планлаштыру документын эшләү өчен Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы җаваплы булып тора.

---